## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Иске Кырлай авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**“24” ноябрь 2023 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Иске Кырлай территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

**1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Иске Кырлай авылында юл-урам челтәре өчен торба сатып алу - 2 данә;

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Иске Кырлай авылы Хади Такташ урамы;

**2. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- Иске Кырлай авылында скважина өчен насос сатып алу-1 данә.

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 220 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 112 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 106 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 6 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Иске Кырлай авылында халык жыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Иске Кырлай территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

**1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Иске Кырлай авылында юл-урам челтәре өчен торба сатып алу - 2 данә;

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Иске Кырлай авылы Хади Такташ урамы;

**2. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- Иске Кырлай авылында скважина өчен насос сатып алу-1 данә.
- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12А йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.